ЕЛАБУЖСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ ИНСТИТУТ
КАФЕДРА ПСИХОЛОГИИ
ЕЛАБУЖСКОЕ ГОРОДСКОЕ УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ
ТАТАРСКАЯ ГИМНАЗИЯ № 1 г.ЕЛАБУГИ

Печатается по решению Ученого Совета ЕГПИ

**«Татарстан республикасы инновацион гомумбелем мәктәпләренең укыту-тәрбия процессына националь-региональ компонентны керту»**
мәктәп директорларының региональ киңәшмәсе материаллары буенча фәнни-методик тупланма. Алабуга, 1998, 136 б.

**«Внедрение в учебно-воспитательный процесс инновационных общеобразовательных школ Республики Татарстан национально-регионального компонента»**
учебно-методический сборник по материалам регионального совещания директоров школ. Елабуга, 1998, 136 с.

Научные редакторы: доцент **Мухаметзянова Ф. Г.**
доцент **Шаймарданов Р. Х.**

Рецензенты: профессор **Исмагилова С. Г.**
методист ГУО **Салихова Р. Г.**

**Елабуга, 1998.**

Зур гәүдәле, бик көчле
Ике зур казык тешле
Торган җире тропик ил
бу - озын борынлы... /фил/

Табышмакның җавабын дөрес таптыгыз. Хәзер фил турында шигырь тыңлагыз.

Фил бүрәнә ташып йөри
Кара урман эчендә
Һаман күз алдымда тора
күрсәм дә тик ... төшемдә

II. Китап белән эш

1.Балалар, хәзер сез үзалдыгызга «Фил» текстын укып чыгыгыз. Гөрләп укыйбыз. Сорауларга җаваплар бирү.

2.Хәрефләр адашкан уен.

Без фил турында сөйләшкәндә хәрефләр таралышканнар, адашканнар. Алардан сүзләр төзергә кирәк.

ӘНФИӘС

3. Фонетик анализ.

Нәфисә сүзенә фонетик анализ ясау. / ничә аваз, хәреф, сузык, тартык яңгырау, саңгырау/

4.73 бит. Сүзләрне чылбырлап эшләү.

5. «Фабрика» тексты өстендә эшләү.

-Курчак киеме буенча әңгәмә. Нәрсә кигән /шарф, кофта/

Укучылар безнең әниләребез, әбиләребез бәйләп кигезергә тырышалар. Күп очракта без кибетләрдән әзер бәйләнгән әйберләр сатып алабыз. Аларны фабрикада бәйлиләр.

-Хәзер мин сезгә шул турыда укып үтәм.

-Текстагы [ф] булган сүзләрне табып уку.

Йомгаклау.

**Ф. М. ИСМӘГЫЙЛОВА**
*Алабуга дәүләт педагогия институты доценты*

## ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ – БЕРГӘ ГОМЕРГӘ

Кайсы гына фанне алма, үзенең беренче яралгыларын ул халыкның тормыш-көнкүреш ихтыяҗларыннан чыгып, күк йөзеннән, кояш, ай, йолдызларны өйрәнү, күзәтү нәтиҗәсендә туган тәҗрибәсеннән ала. Игенен иккән безнең халык, малын асраган, кортчылык белән шөгыльләнгән, җиләк-җимеш җыеп һәм үстереп көн иткән. Үлән-чәчәкләрне дәва чарасына эверелдергән, әби-бабаларыбызга кояшның кайчан һәм ничек

чыгуы һәм батуы, айның калку һәм сүнүе, йолдызларның ничек җемелдәве, йолдыз-болытларның ни рәвешле алмашынып торуы кирәкле мәгълүмәтларны биреп торган. Аннары дөнья гизәргә һәм сәүдә итәргә һәвәс халкыбыз, йолдызларга карап, юлын салган, кирәкле кала һәм базарларга вакытында барып җитә алган.

Тупланган тәҗрибә чын мәгънәсендәге аң-белем, сынамышлар, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, әкият, легенда, җыр, риваятьләр булып, халык күңелендә уела килгән. Дәресләрдә һәм класстан тыш эшләрдә укучыларны шулар белән таныштыру, буыннан-буынга җыелып, сакланып, баеп һәм камилләшкәннән-камилләшә барып, күчеп килгән бу кадерле нигъмәтләрне уку-укыту-тәрбия процессына кертеп җибәрү милли-региональ компонентның гаять мөһим тармагы булып санала да инде. Бигрәк тә астрономия курсын укытканда бу шулай. Аның һәр бүлегенә фольклор жанрларының теләсә кайсыннан үрнәкләр иксез-чиксез, һәм шуны беренче дәрестән башлап, ел ахырына кадәр күзәтә барырга мөмкинлекләр гаять киң.

Мисал итеп «Астрономия предметы» дигән темага иң беренче дәресне китерик. Анда мөгаллим укучыларга астрономиянең күк җисемнәренең хасиятен һәм хосусиятен өйрәнүче фән икәнлеген, бу фәннең чишмә башы халыкның тормыш-көнкүреш, иҗтимагый тормышка җайлашу һәм анда үз урынын анык билгеләү тәҗрибәсеннән, вакыт һәм пространствода ориентлашу ихтыяҗларыннан туган мәгълүматлар икәнлеген төшендерә.

- Безнең төрек бабаларыбыз, - ди мөгаллим, - гомер-гомергә оста сәүдәгәр булган, илләр гизәргә, дөнья күрергә яраткан. «Йөргән таш шомара, яткан таш мукләнә» кагыйдәсеннән чыгып, үзе өчен кирәкле ачышлар ясаган, компассыз-нисез һәм картларсыз ай-йолдызларга, кояш йөрешенә карап, чүлләр, далалар аша юл сарган. Күргән-белгән, тапкан-өйрәнгән, сизелгән-тоелганнардан нәтиҗәләр, матур яңгырашлы, тирән мәгънәле һәм үткән мәкаль һәм әйтемнәр, эндәшүләр, табышмаклар, риваятьләр, мәзәкләр булып формалашып, халык арасында таралганнар, буыннан-буынга тапшырылганнар...

Алга таба укучылар табышмаклар әйтешәләр:

- Табак тулы җиз төймә, кулым сузып алалмыйм. (Күк, йолдызлар.)

- Вак кынадыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре. (Йолдызлар.)

Дәрестә мәкаль һәм әйтемнәр китерелә:

- Җыен йолдыз җыелса да, яктылыгы айдай юк.

- Ай белән Кояш берәр генә була.

- Кояш бик зур да, аны капларга бик кечкенә болыт та җитә. һ.б.

Ай-йолдызлар белән бәйле сынамышлар да җитәрлек. Алар - халыкның күк җисемнәрен күзәтү, өйрәнү, тикшерү һәм кир.к сөземтәсен чыгару нәтиҗәсе булып торалар.

- Йолдыз атылса, җил булыр.
- Йолдыз тирәсендә кара алка булса, яңгыр булыр.
- Йолдызлар куе күренсә, аяз булыр һ.б.

Дәрес ахырына таба укучылар кояш һәм ай-йолызлар образ итеп алынган җырлар тыңлыйлар:

Һава йолдыз ничәдер,
Ничә генә баксаң, күчәдер;
Ничә генә айлар, ничә еллар
Гомерләрем заигь үтәдер.

Һаваларда йолдызиләк-иләк,
Җидегән йолдыз бик сирәк;
Ачы ла дөньяны көтәр өчен
Арысландай батыр ир кирәк.

Яшәвенең күп өлешен борынгыдан әнә шулай табигать белән турыдан-туры бәйләнештә үткәргән татар халкы табигать матурлыгына, аның көчләренә, күренешләренә, хәрәкәтләренә, буяу-төсмәләренә карата сизгер булган, алар белән кызык - сынган, тирәнтен аңлаган, аның күренеш - хәрәкәтләрен җырларына матурлык, сагыну, сагышлану, ярату, соклану образлары буларак кертеп, үзенең хис-кичерешләрен, табигать дөньясының бер әгъзасы ианлеген чагылдырган. Җырның төзелешенә генә кара: беренче өлешендә аның табигать, аның ай-йолдызлары; шулар фонында инде соңгы ике юлына - хис-кичерешләр. Чыны белән табигать һәм Кеше - бергә гомергә.

**Р.Н. НИГЬМӘТУЛЛОВА**
*Алабуга 1 нче татар гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты буенча*
*укытучы-методист*

# ФИГЫЛЬ ТУРЫНДА ТӨШЕНЧӘ БИРҮ

МАКСАТ: башлангыч сыйныфларда алган белемнәренә таянып, фигыль турында белемнәрне яңарту; терәк схема нигезендә фигыль турындагы белемнәрне системага салу, иҗади фикер йөртү сәләтен, сөйләм телен үстерү.

ҖИҺАЗЛАУ: дәреслек, терәк схема, «Телстан планетасы» - карта, «Кыш» картинасы, «Ромашка» уены.